
# *Нәҗметдинов Надир Нәҗметдин улы*



*Мин, Нәҗметдинов Надир Нәҗметдин улы , 1939нчы елның 7 нче маенда Кече Битаман авылында туганмын. Сугыш башланганда миңа 2 яшь булган. Сугыш башланганның икенче көнендә үк әтине сугышка алганнар. Сугыш вакытын кечкенә булганлыктан хәтерләмим.*

*Балачак бик авыр булды. Ачлыктан интектек. Күңел әрнегән вакытлар, гаделсезлекләр бик күп булды. Ярдәм итүче генә булмады. Әти, әтинең ике энесе сугышта үлеп калды. Бу хәлләрне бик авыр кичердек.*

*Язгы кычыткан, өшегән бәрәңге ашап яшәдек. Колхозда 1955 нче елга кадәр хезмәт хакы бирмәделәр. 1950-1958 нче елларда колхозда эшләдем. Җиде ел белем алдым. 1972 нче елда 10 нчы классны бетердем.*

*Сугыш бетү хәбәрен утын алып кайтып килгәндә ишеттек. Безнең туганнардан кайтучылар булмады. Сугыштан соң да бик авыр яшәдек, бөтен әйберне сатып бетердек. Хәзерге яшьләргә теләгем шул: гаделсезлеккә каршы көрәшсеннәр иде.*